***Игелек эшләүченең һичкайчан эче пошмас, рәхәтлектә гомер кичерер.Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычларын намус белән үтәп киләләр, һәркем бәхетле, сөекле булуны теләр. Ләкин сөекле булу өчен бер генә юл бар – башкаларга изгелек итү.***

***(Ризаэтдин Фәхреддин сүзләре)***

Без – тимурчылар. Тимурчыларның төп вазыйфасы: тыл, сугыш, хезмәт ветераннарына кулларыннан килгәнчә ярдәм итү. Без 6 А нчы сыйныф укучылары Мөхәммәтҗанова Асия Хөснетдин кызына булышабыз. Аның янына һәр атнаның чәршәмбесендә барабыз. Асия әби Гатаулла бабай белән 5 бала тәрбияләп үстергәннәр. Балалар үсеп-буйга җитеп, төрлесе-төрле якка таралышып беткәннәр. Асия әби бүгенге көндә берьялгызы. Алар Гатаулла бабай белән 80 яшькә кадәр тигез гомер иткәннәр. Моннан 2 ел элек кенә бабай гүр иясе булган. Балалар, әлбәттә, ял, бәйрәм көннәрендә әниләренең хәлен белеп, өен, хуҗалыгын карап торалар. Безнең шау-гөр килеп керүебез, Асия әбине бик куандыра. Кулыбыздан килгәнчә, вак-төяк эшләрен эшлибез.Кышын кар көрибез, язга чыккач бакчасын казышабыз. Ул безнең килүебезне түземсезлек белән көтеп кала.

Рәхмәт яусын балалар! Исән-сау булыгыз, исән-сау укыгыз, - дип теләкләр тели-тели һәм икенче атнага да килүебезне көтеп, безне озатып кала. Без әле кечкенәләр,шулай да, юк кына нәрсә белән дә, 80 яшьлек карчыкны сөендерүебез өчен без бик шат.


СПЕШИТЕ ДЕЛАТЬ ДОБРО!









